СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2022 г. Агрыз № 22-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 6 өлеше, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елнын 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы белән, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 48 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 15.11.2013 елның 28-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 26.10.2022 елның 20-3 номерлы карары белән билгеләнгән кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе мәгълүматларын һәм конкурс нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына Шәрипов Рөстәм Рәшитовичны билгеләп куярга.
2. Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясындагы 7 өлешендә билгеләнгән форма буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт төзергә.
3. Әлеге карарны “Татмедиа” АҖ филиалының “Әгерҗе хәбәрләре” (“Агрызские вести”) газетасында, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

Совет Рәисе
Муниципаль район башлыгы А.Р. Вәлиев